**“Актүбә 2 нче урта гомуми белем бирү мәктәбендә**
**“Халыкара туган телләр көне”нә багышлап уздырылган чараларга отчет**

Татар теленә мәхәббәт уяту һәм телебезгә игътибарны арттыру, укучыларның интеллектуаль һәм иҗади потенциалын үстерү максатыннан 18. 02. 2019 – 23. 02.2019 аралыгында “Халыкара туган телләр көне”нә багышлап атналык үткәрелде. Ул “Халыкара туган телләр көне” кысаларына туры китерелде. Атналык укытучыларга һәм укучыларга телебезнең әһәмиятен һәм мәктәбебездә туган телнең, инглиз теленең тоткан урынын тагын бер тапкыр күрсәтергә мөмкинлек бирде. Чаралар алдан төзелгән план буенча алып барылды. **(План алдагы биттә)**

## *15нче февраль*

### “ Җәлил исеме үлемсез” әдәби кичә

Укучыларны Муса Җәлилнең тормыш юлы, иҗаты һәм сугышта күрсәткән батырлыклары, җәлилчеләр турында белемнәрне арттыру, М.Җәлил шәхесе һәм Җәлилчеләр белән горурлану, соклану хисләре тәрбияләү, сөйләм телен үстерү, баету максатыннан туган тел һәм әдәбияты, инглиз теле укытучысы Кашапова Ф.И. **15 нче февраль көнне** 4 нче б сыйныфында “ Җәлил исеме үлемсез” дип исемләнгән әдәби кичә уздырды. Укучылар үзләренең шушындый матур, тыныч тормышта яшәүләре белән Муса Җәлил кебек шагыйрьләргә, Җәлилчеләргә, кадерле ветераннарыбызга бурычлы булуларына тагын бер кат инандылар.



Утвержден
Директор МБОУ «СОШ №2 п.г.т.Актюбинский»
__________ / Марданшин А.И./

**План мероприятий по проведению Международного дня родного языка МБОУ «СОШ№2 пгт Актюбинский»(18.02.2019 – 23.02.2019)**

**Халыкара телләр көненә план**

| № | Наименование мероприятия | Дата | Класс | Ответственный |
|---|---|---|---|---|
| 1. | Открытие недели.Атналыкны ачу.<br>Заучивание стихотворений Г.Тукая «Туган тел» на татарском и русском языках. Г.Тукайның "Туган тел"шигырен рус һәм татар телендә ятлау.<br>Сыйныфтан тыш чара. | 18.02 | 1-4<br><br>2б | Кашапова Ф.Ә. Башлангыч сыйныф укытучылары<br><br>Гаскарова Э.М. |
| 2. | Открытое мероприятие на английском языке<br>«История Великобритании» | 18.02 | 9а | Чернова С.К. (учитель иностранного языка) |
| 3. | Экскурсия в детскую библиотеку | 19.02 | 1а, б | Байгузина Т.Ә. Закирова Э.С. |
| 4. | Дидактическая игра.<br>«Раскрась и запомни»<br>Игра «Отгадай сказку»<br>«Укрась тюбетейку и калфак» | 19.02 | 1а, б<br>2а,б<br>3а,б | Татар теле һәм әдәбияты укытучылары |
| 5. | Открытое мероприятие на английском языке<br>«Достопримечательности США» | 20.02 | 6а | Галеева А.Р.(учитель иностранного языка) |
| 6. | По улицам М.Джалиля. Путеводитель | 20.02 | 4б | Кашапова Ф.И. |
| 7. | Устный журнал. Телдән журнал.<br>« Международный день родного языка», «Чем богат родной язык», «Какой язык твой родной» «Татарский и русский национальные костюмы» | 21.02. | 1-11 | Татар теле һәм әдәбияты укытучылары |
| 8. | Муниципальный этап конкурса «Всероссийский мастер-класс учителей родного, включая русский, языков» | 21.02 | | Шагалиева Г.Н. |
| 9. | Круглый стол по творчеству М.Джалиля. | 21.02 | 10а | Гаскарова Э.М. |
| 10. | Игра-драматизация по сказке «Колобок» | 20.02 | 4а,б | Хазиева Р.Д. |
| 11. | Рисование по мотивам стихотворений М.Джалиля<br>М.Җәлил шигырьләренә иллюстрация бәйгесе | 20.02. | 2-4 | Татар теле һәм әдәбияты укытучылары |
| 12. | М.Җәлилнең биографиясе һәм иҗаты буенча викторина | 22.02 | 7а,б | Муртазина Л.И. |
| 13. | Посещение мини-музея «Татарская изба» | 22.02. | 5а, б | Кашапова Ф.Ә. |
| 14. | "Туган тел бәйрәме". Конкурс чтецов | 22.02 | 4Б | Закирова Э.С. |

# *18нче февраль*

18 нче февраль көнне мәктәбебездә Халыкара телләр көненә багышланган атналык башланды. 8 нче  А сыйныф укучылары белән сөекле шагыйребез Г.Тукайның “Туган тел” шигырен татар һәм рус телләрендә башкардык.

**Песня на слова татарского поэта Тукая**
Туган тел / Родной язык
И туган тел, и матур тел, әткәм-әнкәмнең теле!
Дөньяда күп нәрсә белдем син туган тел аркылы.
Иң элек бу тел белән әнкәм бишектә көйләгән,
Аннары төннәр буе әбкәм хикәят сөйләгән.
И туган тел! Һәрвакытта ярдәмең берлән синең,
кечкенәдән аңлашылган шатлыгым, кайгым минем.
И туган тел! Синдә булган иң элек кыйлган догам:
ярлыкагыл, дип, үзем һәм әткәм-әнкәмне, ходам!
О, как хорош родной язык, отца и матери язык,
Я в мире множество вещей через тебя навек постиг!
Сперва на этом языке, качая зыбку, пела мать,
А после - бабушка меня старалась сказкою унять.
Родной язык, ты мне помог понять и радость с малых лет,
И боль души, когда в глазах темнеет, меркнет ясный свет.
Ты мне, родной язык, изречь молитву первую помог:
"Прости меня, отца и мать, великодушен будь, мой Бог!"




18 нче февраль көнне2 б сыйныф укучылары Халыкара телләр көне атналыгы кысаларында чарада катнаштылар. Укучылар кошларга ярдәм йөзеннән җимлекләр ясадылар.Һәм кошларга ярдәм иттеләр.





**9 нчы А сыйныфында инглиз телендә “Бөекбритания тарихы” дип аталган чара уздырылды**

“Халыкара телләр көннәре” атналыгына багышлап, 9нчы А сыйныфы укучылары катнашында (Укытучы Чернова С.К.) инглиз телендә “Бөекбритания тарихы” дип аталган чара үтте. Укучылар Бөекбритания тарихын, мәдәнияте, гореф-гадәтләре белән читтән торып танышты. Чара бик эчтәлекле итеп оештырылган иде.




# 19 нчы февраль

**Актүбә бистәсенең китапханәсенә экскурсия**

19 нчы февраль көнне 1 нче В сыйныфы укучылары Байгузина Т.Ә. кызы җитәкчелегендә Актүбә бистәсенең китапханәсенә экскурсиягә барды, беренче тапкыр “Китап дөньясы”на сәяхәт ясадылар.Укучылар үзләренә кызыклы китап сайладылар






# 20 нче февраль

***АКШ та истәлекле урыннар***

В рамках недели родного языка учащиеся 6А класса подготовили сообщения о достопримечательностях США. Было увлекательно и интересно узнать о знаковых местах этой большой и колоритной страны.

In the framework of the week of the native language, students of grade 6A prepared reports on the sights of the United States. It was fascinating and interesting to learn about the iconic places of this large and colorful country.

6 нчы А сыйныфы укучылары укытучылары Галеева А.Р. белән читтән торып Америка Кушма штатлары буйлап истәлекле урыннарга “сәяхәт”кылдылар.





20 нче февраль көнне 2-4 нче сыйныфлар арасында Муса Җәлил шигырьләренә иллюстрация бәйгесе үтте.



**Түгәрәк өстәл артында сөйләшү**

10 нчы А сыйныфында Муса Җәлилнең тууына 113 ел тулу уңаеннан М.Җәлилнең иҗаты буенча түгәрәк өстәл артында сөйләшү булды. Бу истәлекле дата уңаеннан Феоктистова Ульяна, Шарипов , Салахова Ленизa язып килгән рефератларын укыдылар. Дәрес ахырына укытучылары Эльвира Мәхмүтовна Муса Җәлил турында белемнәрен тикшерү өчен тест бирде. Укучылар

герой-шагыйрь Муса Җәлилнең иҗаты,батырлыгы белән горурлануларын белдерделәр.. Ул һәрвакыт безнең күңелләрдә.



# 21 нче февраль

**Без татарча сөйләшәбез**

21 нче февраль – Халыкара туган тел көне. Бу көнгә багышлап 3В һәм 7Б сыйныфлары рус төркемнәрендә туган тел «татар телендә» аралашу дәресе узды.





7 нче Б сыйныфы укучылары арасында әрмән, рус һәм татарлар укый. Һәрбер милләт үз ана телендә матур итеп шигырь сөйләде. Дәрес ахырында “Без сөйлибез дуслык телендә” дип шигырь юллары белән әңгәмә тәмамланды.




4 нче б сыйныфында “М.Җәлил урамы буйлап” темасына  сәяхәт-дәрес үтте.




## 21нче февраль



**Бөтенроссия ана теле һәм рус теле укытучыларының мастер – классы бәйгесендә беренче категорияле туган тел һәм әдәбияты укытучысы Шагалиева Гөлназ Нәҗип кызы актив катнашты.**




# *22 нче февраль*

## Туган тел бәйрәме

“И туган тел, и матур тел...” дип исемләнгән чарада 6А, 6Б сыйныфы укучылары катнашты. Моңлы җырлар, дәртле биюләр, сәнгатьле укылган шигырьләр һәркемнең күңеленә хуш килде.



**Туган төбәкне өйрәнү музееның “Татар өе” мини - музеен укучылар үз итте.**



Милли мәгариф эшләре буенча директор урынбасары________/Кашапова Ф.А./

24.02.2019